Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегенең Красновидово авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

2019 ел, 16 декабрь № 3

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 9 нчы декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Красновидово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

-авыл эчендәге , урамара юлларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту;

-су чыгынакларын һәм сuүткәргечләрне төзекләндерү.

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 351 кеше кертелгән, 184 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 184 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлегенә керүче Красновидово авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Красновидово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

-авыл эчендәге , урамара юлларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту;

-су чыгынакларын һәм суүткәргечләрне төзекләндерү.” мәсьәләсе буенча карар кабул итәргә.

3.2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Красновидово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-авыл эчендәге , урамара юлларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту;

-су чыгынакларын һәм сусаткаргечләрне төзекләндерү.

4. Халык җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк урамы, 3;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
«Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Красновидово авыл җирлеге Советы рәисе В. П. Оленин